СОВЕТ КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.09.2018 д. Канаш №45-205

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017елның 27 сентябрендәге 30-136 номерлы карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең әлеге проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча халык алдында

тыңлауларны 2018 елның 11 октябрендә 10.00 сәгатьтә авыл клубы бинасында, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Нижнее Озеро  авылы Үзәк урамы 7 йорт адресы буенча уздырырга.

4. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерү һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Канашавыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә  тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге  башлыгы Н. Н. Вальков